| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

от 14.10.2020 г. Казань № 109-5/т-2020

Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны тормышка ашыру хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар карар үз көченә кергән вакыттан бирле гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципаль маршрутлары буенча җәмәгать транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 21 апрелендәге 7-2/т номерлы;

«Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 21 июнендәге 7-2/т номерлы.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 14.10.2020
№ 109-5/тп-2020 карарына кушымта

Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр бару һәм бер урынлы багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тариф (сум) | |
|---|---|---|
| | бер тапкыр бирелә торган билет сатып алганда | 100 һәм аннан да күбрәк барган өчен озак файдаланыла торган билет белән түләгәндә[1] |
| Автобус | 25 | 20 |
| Трамвай | 25 | 20 |

<1> күрсәтелгән вакыт эчендә юл өчен саны билгеләнгәнчә бару хокукын бирә торган озак файдаланудагы билет белән түләгәндә.

Искәрмә. Багаж алып бару бәясе юл йөрү бәясеннән аерым түләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге